ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында" Федераль законның $16^{6}$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында" Федераль законның $16^{6}$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында" 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә "$16^{6}$ статьясын" сүзләрен "$16^{6}$ һәм $16^{6-1}$ статьяларын" сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон "Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында" 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $16^{6}$ статьясындагы 36 өлеше, $16^{6-1}$ статьясындагы 20 өлеше нигезендә Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба – Фонд) эконом класслы торак төзү өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен, түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага (алга таба – эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда), шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, шул исәптән эконом класслы торакны һәм башка торак төзелешен минималь таләп ителә торган күләмдә төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен арендага (алга таба – эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү

өчен аренда) тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом классны торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар (алга таба – эконом класслы торак) сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлек) кертү тәртибен, аерым алганда, чиратлылыгын билгели.";

3) 2 статьяның 2 өлешендә:

а) 2 пунктта "(үтенечнамәләрне)" сүзеннән соң ", эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен Фондның җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар уздыру турында үтенечнамәләрне" сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) Федераль законның $16^{6}$, $16^{6-1}$ статьялары нигезендә Фонд федераль милектәге җир кишәрлекләрен яисә Фондның җир кишәрлекләрен эконом класслы торак төзү өчен мондый җир кишәрлекләреннән түләүсез вакытлыча файдалану яисә аларны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукционнар, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар (алга таба – аукцион) уздыру максатларында сайлап алу буенча чаралар үткәргәндә Федераль законда каралган тәртиптә Фонд белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;";

4) 3 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы:";

5) 5 статьяның 5 өлешендә ", торак йортларның (шул исәптән индивидуаль торак төзелеше объектларының)" сүзләрен "һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларның, индивидуаль торак йортларның" сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 статьяда:

а) 1 өлештә "аренда шартнамәсе" сүзләреннән соң ", эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен Фондның җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе" сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә "аренда шартнамәсе" сүзләреннән соң ", эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе" сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә "аренда шартнамәсе" сүзләреннән соң ", эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе" сүзләрен өстәргә;

г) 6 өлештә "муниципаль берәмлек башлыгы" сүзләрен "җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы" сүзләренә алмаштырырга, "аренда шартнамәсе" сүзләреннән соң ", эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда шартнамәсе" сүзләрен өстәргә;

д) 7 өлештә "Муниципаль берәмлек башлыгы" сүзләрен "Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы" сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлештә "Муниципаль берәмлек башлыгы" сүзләрен "Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы" сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 өлештә "2 пунктында" сүзләреннән соң "һәм $16^{6-1}$ статьясындагы 30 өлешенең 2 пунктында" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 3 марты
№ 13-ТРЗ